| | |
|---|---|
| Педагогик киңәшмә утырышында<br>кабул ителде<br>Беркетмә № 1<br>«28» 08 2020 ел | РАСЛЫЙМ<br>«Яңа Кырлай балалар бакчасы» мөдире<br>Т.Г.Файзрахманова<br>Боерык № 26<br>«28» 08 2020 ел |

# Татарстан Республикасы
# Арча муниципаль районы
# “Яңа Кырлай балалар бакчасы”ның
# 2020-2021 нче уку елы өчен эш планы

## ЭЧТӘЛЕК


2019– 2020 НЧЫ УКУ ЕЛЫНА АНАЛИЗ.

I. БАЛАЛАР БАКЧАСЫНЫҢ ЭШ ЮНӘЛЕШЕ:

- 2020 – 2021 НЧЕ УКУ ЕЛЫНА МАКСАТ

- 2020 – 2021 НЧЕ УКУ ЕЛЫНА ТӘРБИЯ ҺӘМ БЕЛЕМ БИРҮ ЭШЕНӘ АЛЫНГАН БУРЫЧЛАР.

II. СОЦИАЛЬ АКТИВЛЫКНЫ ҺӘМ ЭШ КВАЛИФИКАЦИЯСЕН ҮСТЕРҮ.

III. ИНСТРУКТАЖЛАР. ХЕЗМӘТНЕ САКЛАУ. ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮЧЕ ПЕРСОНАЛ ӨЧЕН КОНСУЛЬТАЦИЯ.

IV. МЕТОДИК ЭШ. ПЕДАГОГИК КИҢӘШМӘЛӘР.

IV.1. ТӘРБИЯ ҺӘМ БЕЛЕМ БИРҮ ЭШЕН ТУЛЫЛАНДЫРУ.

IV.2. ТӘРБИЯЧЕГӘ КОНСУЛЬТАЦИЯЛӘР.

IV.3. ТӘРБИЯЧЕ ЯРДӘМЧЕСЕ ӨЧЕН КОНСУЛЬТАЦИЯЛӘР.

V. СМОТР – КОНКУРСЛАР, КҮРГӘЗМӘЛӘР.

5.1 КОНКУРСЛАР, КҮРГӘЗМӘЛӘР, АЧЫК МЕРОПРИЯТИЕЛӘР.

VI. ТЕЛЛӘР ТУРЫНДАГЫ ЗАКОННЫ ТОРМЫШКА АШЫРУ БУЕНЧА ЭШ ПЛАНЫ.

6.1 ДӘҮЛӘТ ТЕЛЛӘРЕНӘ ӨЙРӘТҮДӘ УМКны КУЛЛАНУ БУЕНЧА ЭШ ПЛАНЫ.

VII. ТӘРБИЯ ҺӘМ БЕЛЕМ БИРҮ ЭШЕНӘ ҖИТӘКЧЕЛЕК ИТҮ ҺӘМ КОНТРОЛЬ.

7.1 ОПЕРАТИВ ТИКШЕРҮЛӘР.

7.2 ТЕМАТИК ТИКШЕРҮЛӘР.

VIII. ЭТНО – МӘДАНИ ТӨБӘКАРА ҖЫЕЛМАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУ БУЕНЧА ЭШ.

IX. ӘТИ – ӘНИЛӘР БЕЛӘН ЭШ.

9.1 ГОМУМИ ӘТИ – ӘНИЛӘР ҖЫЕЛЫШЫ.

9.2 ӘТИ – ӘНИЛӘР БЕЛӘН ЭШ ПЛАНЫ.

X. АДМИНИСТРАТИВ-ХУЖАЛЫК ЭШЛӘРЕ.

XI. СӘЛАМӘТЛӘНДЕРҮ, ЧЫНЫКТЫРУ ПЛАНЫ.

XII. ТЕРРОРИЗМГА КАРШЫ ҮТКӘРӘ ТОРГАН ЧАРАЛАР ПЛАНЫ.

XIII. КОРРУПЦИЯГӘ КАРШЫ КӨРӘШ АЛЫП БАРУ БУЕНЧА ЭШ ПЛАНЫ.

**2019-2020 нчы уку елында эшләнгән эшләргә анализ**

Яңа Кырлай балалар бакчасы Яңа Кырлай авылы Үзәк урам 2 нче йортта урнашкан. Узган уку елында бакчага 22 бала йөрде, 1 катнаш төркем эшләде. Балаларга белем-тәрбия бирүдә, кызыксынучанлыкларын, фикерләү сәләтләрен үстерүдә, чисталыкка–пөхтәлеккә өйрәтүдә 4 хезмәткәр көч куйды.

Балалар бакчасы ел буе балаларга эзлекле белем бирү, физик яктан чыныккан, сәламәт, табигатьне саклый белүче балалар тәрбияләү бурычлары өстендә эшләде. Белем һәм тәрбия бирүнең беренче баскычы булган мәктәпкәчә тәрбия бирү учреждениеләренең эшен нәтиҗәле итү өчен яңа идеяләр, белем-тәрбия бирүдә инновацион технологияләр куллану кирәк.

Безнең балалар бакчасы педагоглары яшь буынны тәрбияләүдә яңа чаралар, белем-тәрбия бирүнең нәтиҗәле методларын табып, кулланып, 2019-2020 нче уку елында уңышларга ирештеләр. Бакчада балаларның физик, интеллектуаль һәм шәхси үсешен тәэмин итү, иҗат мөмкинлекләрен ачу һәм үстерүгә нык игьтибар ителде. Тәрбиячеләр балаларга белем-тәрбия бирүдә заман таләпләренә туры килә торган программаларга нигезләнеп эшләделәр. Бу программалар үз алдына балаларны бар яклап та сәламәт шәхес итеп үстерү, аңа мәктәптә уку–тәрбия алу өчен кирәкле психологик процесслар булдыруны максат итеп куя.

Тәрбияче тарафыннан балалар бакчасының укыту-тәрбия планнары, шөгыльләрнең расписаниесы һәм календарь планнары төзелде, бакча мөдире тарафыннан расланды һәм гамәлгә кертелде. Ел дәвамында шул расписание буенча тәрбияче даими рәвештә балалар белән шөгыльләр алып барды.Балаларының сәламәтлеген саклау, ныгыту хәзерге көндә ата-аналарны, педагогларны иң борчыган мәсәләләрнең берсе. Шуннан чыгып үз алдыбызга түбәндәге мәсьәләләрне куйдык:

- хәрәкәт - бала өчен иң кирәкле шарт булуын күз уңында тотып, бакчада хәрәкәтле уеннарны үз югарылыгында уздыру;
- туклану - бала организмы өчен иң мөһиме шарт, шуңа күрә менюны сәламәтлекне саклау технологиясенә нигезләнеп төзү;
- организмны чыныктыру нәтиҗәсендә баланың салкынга, эссегә, авыруларга каршы торучанлыгын арттыру, чыныктыруны һәр балалның үзенчәлекләрен искә алып оештыру;
- балаларның бакчадан тыш вакытын дөрес оештыру буенча ата-аналар белән әңгәмәләр үткәрү;
- мәктәпкәчә яшьтәге балачак - сабыйның психик үсешендәге беренче чор, чөнки бу яшьтә шәхеснең бөтен психик сыйфатларына һәм үзенчәлекләренә нигез салына.

Шуларны истә тотып, баланың һәрьяклакп үсеше өчен гаиләнең тәрбияче белән үзара аңлашып, ярдәмләшеп эшләвен булдыру.

Кыскасы, балаларны сәламәт рухта тәрбияләү – балалар бакчасының изге бурычы, чөнки балаларның күп вакыты бакчада уза, ул аларның икенче өе булып тора. Шунлыктан бакчада нәниләр өчен барлык уңай шартларны тудырырга тырыштык. Балаларның сәламәтлеген саклау, ныгыту, аларның физик һәм интеллектуаль үсешен тәэмин итү йөзеннән, эшебезне планлаштырудан башладык, планнарны балалар бакчасының эшен камилләштерү буенча үзгәрешләр кертеп һәм яңа бурычлар куеп оештырдык. Яшь үзенчәлекләренә туры китереп һәр төркемдә чыныктыру планы төзелде, аның буенча эш оештырылды; Арча участок больницасы педиатры тарафынан балаларны тикшерү үткәрелде. Тәрбиячеләребез көндәлек режимны төгәл үтәп, белем-тәрбия бирү эшен дөрес оештырды. Иртәнге гимнастика, физкультура занятиеләре ел буена программага нигезләнеп, тиешле дәрәҗәдә алып барылды. Физкультура дәресләрендә иң беренче балаларның активлыгына игътибар ителде, дәрес уздыру төрләре үзгәртелде, яңалыклар кулланылды.

Бакчада физкультура дәресе зурлар төркемендә өч тапкыр уздырылды - дәреснең берсе, һава торышы уңай булганда, ачык һавада узды. Дәресләрдә түбәндәге мәсьәләләрне тормышка ашырдык:

- балаларның үсешенә һәрвакыт игътибарлы булу;
- балаларга тормышта кирәкле хәрәкәт күнекмәләре бирү;
- сәламәтләндерү, чыныктыру эшенә шартлар булдыру;
- балаларның сәламәтлекләрен ныгыту, көчен, җитезлеген үстерү;
- сәламәтләндерү юнәлешендә төрле физик күнегүләр белән даими шөгыльләнүгә ихтыяҗ булдыру;
- заман таләпләренә туры килгән прграммалар куллану, яңалыкка омтылу.

Балаларны сәламәтләндерү программасы түбәндәге эш төрләрен кертеп төзелде:

1- чыныктыру ысуллары;
2- гripптан, салкын тиюдән саклану чаралары;
3- фитотерапия;
4- яссытабанлыкны, күз күреме бозылуны кисәтү;
5- гәүдәне торышына игътибар.

Грипп, ОРЗ чорында группаларда сарымсак инголяциясе ясалды. Эшебезнең нәтиҗәсе - грипп эпедимиясе вакытында бакча карантинга ябылмады, авыручы балалар булмады.

Чыныктыру, сәламәтләндерү процедураларын башкарганда тәрбияче түбәндәге гигиена шартларын һәм таләпләрен төгәл үтәде:

- бүлмә һавасының саф булуы;

- бинадагы һава температурасының нормада булуы;
- киемнәрнең һава температурасына карап дөрес сайлануы;
- актив хәрәкәт режимы.

Бу юнәлештәге эшнең нәтиҗәсе ата-аналардан да бәйле. Без аларга сәламәт яшәү рәвешен формулаштыру принципларын өйшартларында да үтәү кирәклеген искәртеп тордык.

Менюда ризыклар төрләндерелде, балалар аксымга бай продуктлар, үз бакчабызда үстерелгән яшелчә, ел әйләнәсендә җиләк-җимеш белән тукландырылды.

Бакчада ел буена көндәлек режим төгәл үтәлде, йоклар алдыннан аяк кулларны юу, йокыдан торгач балаларның күңелен күтәрү, чыныктыру күнегүләре эшләтелде. Һәр төркемдә буш вакытларда даими рәвештә күз гимнастикасы, аваз әйтү гимнастикалары кертелде. Кыш көне шуар өчен бакча ишегалдында балалар белән бергәләшеп кардан тау, урамга шугалак ясап куйдык. Кыш буе балалар рәхәтләнеп шуларда шудылар, уйнадылар.

Дөрес туклану, көндәлек режимны, сәламәтлек программасын төгәл үтәү, физкультура, спорт белән даими шөгыльләнү, организмны чыныктыру балаларыбыз сәламәтлегенә уңай тәэсир итте: алар азрак авырды.

Бакчабызның бурычы - **Балаларда ана телендә һәм икенче дәүләт теле буларак рус телендә аралашуга үстерелешле тирәлек булдыру, кызыксыну тәрбияләү.** Ел дәвамында балаларны ике дәүләт теленә өйрәтү буенча яңа укыту-методик комплектлар, ИКТ кулланып эзлекле эш алып барылды. Балаларны ике дәүләт теленә өйрәтүне тормышка ашыру максатыннан еллык эш планы, перспектив планнар төзелде һәм план нигезендә даими эш алып барылды. Балалар бакчасы ата-аналар белән тыгыз элемтәдә эшләде. Әти-әниләр белән эш системалы планга нигезләнеп алып барыла. Уку елы барышында төрле формадагы эшләр алып барылды: әти-әниләр җыелышлары «Бала, әти-әни һәм бакча – бердәмлектә көч», «Балаларны туган телдә дөрес сөйләшергә өйрәтү буенча укыту методик комплектлар кулланып эшләүнең әһәмияте», дигән темалар астында үткәрелде. Әти-әниләр белән берлектә системалы рәвештә бәйрәм иртәләре, күңел ачу кичәләре оештырылды һәм үткәрелде.

Һәр ел фасылын зур оешканлык белән каршы алдык. Язын тирә-якны чистартып, апрельдә чәчәк рассадалары утыртып каршыладык. Бакчадагы язгы эшләр белем-тәрбия бирү эшләре белән чиратлап алып барылды: язгы су юлларын ачу, стена буендагы карны чистарту, бакча мәйданын җыештыру уздырылды, чәчәкләрне тәрбияләп үстерү, сирәкләү, су сибү – болар барысы да бакча хезмәткәрләре тарафыннан эшләнде. Көзне каршылап участоктан чәчәк орлыклары, яфраклар җыйдык, мәйданны коелган яфраклардан арындырдык. Кышны каршы алганда исә, кардан сыннар ясау, кар көрәү, кебек эшләр эшләнде, кошларга җим салыр өчен җимлекләр элдек, аларга җим салуны оештырдык. Балаларның экологик белемнәрен киңәйтү, тирәнәйтү максатыннан тәрбиячеләр табигать материалларын туплап, төрле сувенирлар, паннолар ясадылар. Бүлмәләрдә бик күп төрле гөлләр үстердек. Тәрбиячеләр балалар белән берлектә гөлләрне карап, тәрбияләп, гөлләрне таныргa, исемнәрен әйтә белергә өйрәнделәр.

Бу эшләр белән бергә милли һәм бакча традициясенә әйләнгән бәйрәмнәргә дә зур игътибар бирелде, чөнки милли үзаң, милләткә мәхәббәт хисләренә дә нигез мәктәпкәчә белем бирү учреждениеларында салына. Октябрьдә “Сөмбелә” бәйрәме, ноябрь аенда өлкәннәребезгә багышланган “Әнием - алтынкаем” дигән бәйрәм уздырдык, анда балаларның әниләрен чакырдык, кунак иттек. Декабрь аенда Яңа ел бәйрәменә әзерлек барды һәм бәйрәмне һәр елдагыча бик күңелле итеп үткәрдек. Мартта һәр елдагыча зурлап, ныклы әзерлек белән, Әниләр бәйрәме, Нәүрүз, Кошларны каршылау уздырылды. Апрельдә Г. Тукай туган көнен уздырдык, Бөек Җиңүнең 75 еллыгын бәйрәм итәргә әзерләндек. Май ахырында “Сау бул, бакча” бәйрәме уздырылды, бәйрәмгә әти-әниләр һәм укытучылар чакырылды

МАКСАТ:

Кече яшьтәге балаларга рус һэм татар телләрен өйрәтүне яна технологияләргә, яңа алымнарга таянып гамәлгә ашыру .

БУРЫЧЛАР:

1.ФДБС таләпләрен тормышка ашыру шартларында, педагогларның профессиональ компетентлыгын күтәрү.

2.Балаларга дәүләт телләрен өйрәтүдә УМК куллануны системалаштыру.

3. Алдынгы педагогик технологияләр кулланып, балаларның интегратив һәм социаль шәхси сыйфатларын үстереп,программа үтәлеше буенча мониторингның сыйфатын күтәрү .

## II. СОЦИАЛЬ АКТИВЛЫКНЫҺӘМ ЭШ КВАЛИФИКАЦИЯСЕН ҮСТЕРҮ.

| № | Үткәрелә торган чаралар | Үткәрелү вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1. | Тәрбияченең үзбелемен күтәрү өстендә эш планнарын барлау, раслау | Август | Мөдир |
| 2. | Семинар, методик берләшмә утырышларында катнашу. | График буенча | Мөдир, тәрбияче |
| 3. | Социаль активлыкны һәм белем дәрәҗәсен үстерү максатыннан газета-журналларга язылу: "Мәгариф", "Мәгърифәт", "Хезмәт даны", "Дошкольное воспитание", "Ватаным Татарстан", "Тәрбия" һ.б. | Даими | Мөдир<br>Тәрбияче |
| 4. | Иҗади лабораторияне баету, методик материаллар туплау өстендә эш. | Ел дәвамында | Мөдир<br>Тәрбияче |
| 5. | Юл кагыйдәләре (ПДД) почмагын тулыландыру. | Ел дәвамында | Тәрбияче |
| 6. | Методик бүлмәне җиһазлау, яңа материаллар туплау. | Ел дәвамында | Тәрбияче |
| 7. | Мәктәпкәчә тәрбия буенча гомумбелем программасы структурасына федераль дәүләт таләпләре буенча норматив документлар белән актив эшләү. | Август | Мөдир,<br>Тәрбияче |

–

## III.ИНСТРУКТАЖЛАР. ХЕЗМӘТНЕ САКЛАУ. ХЕЗМӘТ КҮРСӘТҮЧЕ ПЕРСОНАЛ ӨЧЕН КОНСУЛЬТАЦИЯ

| №<br>п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр | Үтәлеш |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Куркынычсызлык техникасы, хезмәтне саклау, янгын куркынычсызлыгы буенча агымдагы инструктажлар үткәрү. | Ел дәвамында | Мөдир | |
| 2 | Производство җыелышы: | | | |
| | а) «Хезмәтне оештыру кагыйдәләре» | сентябрь | Мөдир | |
| | б) «Куркынычсызлык техникасы кагыйдәләре үтәлешен тикшерү нәтиҗәләре» | Ел дәвамында | Мөдир | |
| 4 | Гражданлык оборонасы буенча хезмәткәрләр һәм балалар белән эвакуацияләү тренировкалары үткәрү | Квартал саен | Мөдир | |
| 5 | Яңа ел чыршы бәйрәмен үткәргәндә техник һәм янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләренең үтәлеше | декабрь | Мөдир, тәрбияче | |
| 6 | Хезмәтне саклау, янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләренә укыту һәм экзамен (тәрбиячеләр һәм кече тәрбиячеләр өчен) | график буенча | Мөдир,<br>тәрбияче | |
| 7 | Кухня хезмәткәрләрен укыту һәм экзамен алу. | график буенча | Мөдир,<br>тәрбияче | |
| 8 | Медицина күзәтүен, диспансеризация тикшерүен үтүне оештыру | график буенча | Шәфкать туташы(ФАП) | |
| 9 | Хезмәткәрләрне спецкиемнәр һәм кер юу средстволары белән тәэмин итү | ел дәвамында | Мөдир | |

## IV. МЕТОДИК ЭШ

## ПЕДАГОГИК КИҢӘШМӘЛӘР

| № | Үткәреләчәк чаралар, үткәрү вакыты | Үткәрелү вакыты | Җаваплы кешеләр | Үтәлеш |
|---|---|---|---|---|
| | I нче педагогик киңәшмә | | | |
| 1. | *Тема:* Яңа 2020 – 2021 нче уку елына балалар бакчасының эшен оештыру.<br>*Көн тәртибе:*<br>1. 2020 – 2021 нче уку елы өчен эш планын, укыту планын, перспектив планнарны кабул итү, раслау.<br>2. Яңа уку елына әзерлек. Балаларны төркемгә туплау.<br>3.Җәйге сәламәтләндерү чорына йомгак ясау. | Август | Мөдир<br>Тәрбияче | |
| | II нче педагогик киңәшмә | | | |
| 1. | *Тема:* Баланың сәламәтлеген ныгыту, саклау өчен шартлар тудыру тәлапләре".<br>*Көн тәртибе:*<br>1. Балаларны даими рәвештә чыныктыру.<br>2. Шөгель вакытында балалар эшчәнлеген аларның сәламәтлегенә зыян килмәслек итеп оештыру.<br>3. Тематик контроль нәтиҗәләре. | Ноябрь | Мөдир<br>Тәрбияче | |
| | III нче педагогик киңәшмә | | | |
| 1. | *Тема:* Балаларны ике дәүләт теленә дә камил өйрәтүгә яңа укыту-методик комплект ярдәмендә ирешү.<br>*Көн тәртибе:*<br>1. Балаларның татар һәм рус телләрендә актив сөйләмнәрен үстерү.<br>2. Уен технологияләрен куллану.<br>3. Тематик контроль нәтиҗәләре. | Февраль | Мөдир<br>Тәрбияче | |
| | IV нче педагогик киңәшмә. | | | |
| 1. | *Тема:* Узган уку елына нәтиҗә ясау<br>*Көн тәртибе:*<br>1. Балалар бакчасының уку елына алган бурычларның үтәлешенә анализ.<br>2. «Эш нәтиҗәләре» 2020-2021 нче елда белем һәм тәрбия бирү пр. үтәлеше турында тәрбияче отчеты.<br>3. Җәйге чорга сәламәтләндерү планын, эш графигын раслау. | Май | Мөдир<br>Тәрбияче | |

## 4.1. ТӘРБИЯ ҺӘМ БЕЛЕМ БИРҮ ЭШЕН ТУЛЫЛАНДЫРУ

| Кабинет, төркем, | Нәрсә белән тулыландыру | Вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| **мәйданчык** | | | |
| Методик бүлмә | 1. Түбәндәге темага папкалар әзерләү:<br>- Талантлы бала;<br>- Экологик тәрбия бирүдә халык педагогикасы куллану;<br>- (ФГОС) Федераль дәүләт белем бирү стандарты буенча мәгълумат папкасы булдыру;<br>-(ФГОС) Федераль дәүләт белем бирү стандарты буенча тәрбияче өчен стенд.<br>2. Балалар әдәбиятен туплау.<br>3. Башка оешмалар белән килешүләрне төзү (ГИБДД).<br>4. Дидактик рәсемнәр булдыру:<br>- Кыргый хайваннар<br>- Агач-куаклар<br>- Кошлар<br>- Чәчәкләр.<br>5. Методик әдәбият туплау.<br>6.Педагогика һәм психология бүлеген туплауны дәвам итү.<br>7.Кирәкле фонограммаларны булдыру.<br>8.Түбәндәге темаларга күргәзмәләр:<br>- Көзге байлык<br>- Ел фасыллары. | Сентябрь<br>Ноябрь<br>Сентябрь<br>Ел дәвамы<br>Ел дәвамы<br>Сентябрь<br>I квартал<br>Ел дәвамы<br>План буенча<br>План буенча | Тәрбияче<br>Мөдир<br>Тәрбияче<br>Тәрбияче<br>Тәрбияче<br>Тәрбияче<br>Тәрбияче |
| Музыка почмагы | 1. Дидактик уеннар төзү.<br>2. Маскалар ясау.<br>3.Бәйрәмнәр өчен җиһазлар туплау. | Ел дәвамы<br>План буенча<br>Ел дәвамы | Тәрбияче |
| Физкультура почмагы<br><br>Физмәйданчык | 1. Туплар булдыру<br>2. Маскалар ясау.<br>3.Бәйрәмнәр өчен атрибутлар ясау.<br>4. Җиһазларны буяу.<br>5. Перспектив планнар. | Сентябрь<br>Ел дәвамы<br>Ел дәвамы<br>Июнь – август | Мөдир<br>Тәрбияче |
| УМК , ЭРК почмагы | 1.УМК буенча методик әдәбият туплау.<br>2.УМК буенча дидактик уеннар ясау.<br>3.Күргәзмә өчен җиһазлар.<br>4.УМК буенча төзелгән перспектив планнар.<br>5.М.Җәлил турында материал туплау. | Ел дәвамы<br>Ел дәвамы<br>План буенча<br>Сентябрь<br>План буенча | Тәрбияче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | 6.Г.Тукай – материал туплау.<br>7.УМК буенча картиналарны ламинатлау.<br>8.УМК буенча картотека төзү | План буенча<br>Ел дәвамы | |
| ИЗО почмагы | 1. Документларны яңарту.<br>2. Папкаларны яңарту.<br>3. ФДБС буенча декоратив сәнгать төрләрен туплау. | Август<br>Ел дәвамы | Тәрбияче. |
| Төркем бүлмәсе | 1.Әти-әниләр почмагын яңарту.<br>2. Чыныктыру чаралары өчен кирәкле җиһазлар булдыру.<br>3. Сюжетлы – рольле уеннар өчен почмакларгы яңарту.<br>4.Танып-белү эшчәнлеге өчен почмакларны киңәйтү.<br>УМК, ЭРК – мәгълумат стенды тулыландыру. | Сентябрь<br>Декабрь<br><br>Ел дәвамы<br><br>Ел дәвамы<br><br>Октябрь | Мөдир<br>Тәрбияче |

## 4.2. ТӘРБИЯЧЕГӘ КОНСУЛЬТАЦИЯЛӘР

| **№** | **Эш төре** | **Вакыты** | **Җаваплы** | **Үтәлеш** |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Ризыкларны тиешле күләмдә бирү, көндәлек режимны төгәл үтәү. | Август | Мөдир<br>Тәрбияче | |
| 2. | Балалар бакчасында һәръяклап ныклы белем һәм тәрбия бирүне һәр гаиләгә төшендерү. | Сентябрь | Мөдир<br>Тәрбияче | |
| 3. | Акыл хезмәте - авыр хезмәт. | Октябрь | Мөдир | |
| 4. | Физик культура, шөгыльләрдә хәрәкәтле уеннарны төрләндерү. | Ноябрь | Тәрбияче | |
| 5. | Е.В.Колесникова методик ярдәмлеген куллану . | Декабрь | Мөдир<br>Тәрбияче | |
| 6. | Баланы кече яшьтән матур әдәбиятне яратырга ничек өйрәтергә? | Январь | Мөдир<br>Тәрбияче | |
| 7. | Балалар, педагоглар һәм ата – аналар хезмәттәшлегенең бала тәрбияләүдә әһәмияте. | Февраль | Мөдир<br>Тәрбияче | |
| 8. | Балаларның иҗади сәләтләрен үстерүдә җитди нәтиҗәләргә ирешүнең төп шарты: уйланулар, эзләнүләр Мөстәкыйль булырга өйрәтү. | Март | Мөдир<br>Тәрбияче | |
| 9. | Балаларда гади хезмәт күнекмәләрен үстерү. | Апрель | Мөдир<br>Тәрбияче | |

## 4.3. ТӘРБИЯЧЕ ЯРДӘМЧЕСЕ ӨЧЕН КОНСУЛЬТАЦИЯЛӘР

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|

| | | | **кешеләр** |
|---|---|---|---|
| 1. | “Баланың бакчага ияләнү вакытында аларга шәхси якын килү юллары” | Август - сентябрь | Мөдир |
| 2. | «Балаларның дежур торуы белән җитәкчелек итү» буенча практик яктан күрсәтү юлы белән консультация үткәрү | Февраль | Мөдир |

## VI. СМОТР – КОНКУРСЛАР, КҮРГӘЗМӘЛӘР.

| **№ п/п** | **Үткәреләчәк чаралар** | **Үткәрү вакыты** | **Җаваплы Кешеләр** |
|---|---|---|---|
| 1 | Группаның яңа уку елына хәзерлеге.<br>“Көзге могҗиза” яшелчә һәм җиләк-җимешләрдән ясалган поделкалар күргәзмәсе | Октябрь | Тәрбияче |
| 2 | Әниләр көненә багышланган балалар рәсемнәре,кул эшләре күргәзмәсе | Ноябрь | Тәрбияче |
| 3 | Конкурс :<br>а) «Яфраклар композициясе»<br>б) «Кышкы матурлык» әти-әниләр белән берлектә эшләнгән рәсем күргәзмәсе<br>в) “Боз фигуралары патшалыгы” сыннар ясау конкурсы | <br>Сентябрь<br>Декабрь | Тәрбияче<br>әти-әниләр. |

## 5.1 КОНКУРСЛАР, КҮРГӘЗМӘЛӘР,

## АЧЫК МЕРОПРИЯТИЯЛӘР

| **№** | **Үткәреләчәк чаралар** | **Үткәрү** | **Җаваплы** | **Үтәлеш** |
|---|---|---|---|---|

| | | вакыты | Кешеләр | |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Күзге композицияләр күргәзмәсе. | сентябрь | Тәрбияче | |
| 2. | “Сөмбелә” бәйрәме | октябрь | Тәрияче, мөдир | |
| 3. | Әниләр көненә багышланган «Минем яраткан әнием» дигән рәсем күргәзмәсе | ноябрь | Тәрбияче | |
| 4. | “Кар сыннары”. Ата-аналар белән берлектә сыннар ясау конкурсы | декабрь | Тәрбияче | |
| 5. | “Яңа ел” бәйрәме. | декабрь | Тәрияче, мөдир | |
| 6. | “Әтиләр бәйрәме” кичә. | февраль | Тәрияче, мөдир | |
| 6. | Рус халык әкиятләре буенча ясалган рәсем конкурсы. | март-апрель | Тәрбияче | |
| 7. | “Әниләр бәйрәме” кичә. | Март | Тәрияче, мөдир | |
| 8. | Татар халык әкиятләре буенча ясалган рәсем күргәзмәсе | апрель | Тәрбияче | |
| 9. | « Матур җәй, кил безгә!”» - рәсем күргәзмә. | май-<br>июнь | Тәрбияче | |

# VI. ТЕЛЛӘР ТУРЫНДАГЫ ЗАКОННЫ

## ТОРМЫШКА АШЫРУ БУЕНЧА ЭШ ПЛАНЫ

| № | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү | Җаваплы | Үтәлеш |
|---|---|---|---|---|

| п/п | | вакыты | кешеләр | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Һәрбер балага ана телендә төрле яклап үсеш алу өчен шартлар тудыру, аралашу өчен телне сайлап алу иреге белән тәэмин итү. | Ел дәвамында | Мөдир, тәрбияче | |
| 2. | Төркемдә дә тәрбия һәм белем бирү эшен туган телдә (татар телендә) оештыру. | Ел дәвамында | Мөдир, Тәрбияче | |
| 3. | Дәүләт телләре турындагы законны үтәү максатыннан, балаларга татар һәм рус телләрен өйрәтүне оештыру. | Ел дәвамында | Мөдир, Тәрбияче | |
| 4. | Тематик шөгыльләр үткәрү – “Татар телем-анам теле”, “Гаилә гореф-гадәтләре”, “Әбиемнең сандыгы” | кварталга бер | Мөдир, Тәрбияче | |
| 5. | Татар халык бәйрәмнәрен, күңел ачу иртәләре, атналыклар үткәрү-“Сабантуй”, “Нәүрүз”, “Әниемә бүләгем”, “Әтием – минем горурлыгым”. | Ел дәвамында | Мөдир, тәрбияче | |
| 6. | Габдулла Тукайның туган көненә багышлап шигырь бәйрәме үткәрү, конкурсларда катнашу | Апрель | Мөдир, тәрбияче | |

# 6.1 ДӘҮЛӘТ ТЕЛЛӘРЕНӘ ӨЙРӘТҮДӘ УМКны КУЛЛАНУ БУЕНЧА эш планы

| № п/п | Үткәреләчәк чаралар | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр | Үтәлеш |
|---|---|---|---|---|

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Балаларның белем дәрәҗәсен ачыклау өчен диагностика үткәрү | ноябрь, апрель | Тәрбияче | |
| 2. | УМК белән бирелгән дидактик әсбапларны, кассеталарны төркемдә булдыру, әти-әниләрнең алар белән ирекле куллана алуын оештыру. | ел буе | Тәрбияче | |
| 3. | Иҗади отчет атналыгында турыдан туры белем бирү эшчәнлекләрен күрсәтү | квартал саен | Тәрбияче | |
| 4. | Күрсәтмә, таратма материаллар туплауны дәвам итү, яна дидактик уеннар булдыру | ел буе | Тәрбияче | |
| 5. | Әти-әниләр почмагындагы мәгълүмат-ларны алыштырып һәм тулыландырып тору | ел буе | Тәрбияче | |

## VII. ТӘРБИЯ ҺӘМ БЕЛЕМ БИРҮ ЭШЕНӘ ҖИТӘКЧЕЛЕК ИТҮ ҺӘМ КОНТРОЛЬ.

Тәрбияченең балалар белән эшләвен өйрәнү

| № | **Үткәрелә торган чаралар** | **Үткәрелү вакыты** | **Җаваплы** | **Үтәлеш** |
|---|---|---|---|---|
| 1 | Уку елы башы диагностикасын үткәрү,нәтиҗәләр,анализ<br>Уку елы ахыры диагностикасы үткәрү, нәтиҗәләр ясау | Октябрь | Тәрбияче | |
| 2 | Мәктәпкә хәзерлек төркемендә мониторинг үткәрү, нәтиҗәләр ясау, аналитик белешмә язу. | Апрель | Тәрбияче | |

## 7.1 ОПЕРАТИВ ТИКШЕРҮЛӘР

| **№ п/п** | **Үткәреләчәк чаралар** | **Үткәрү вакыты** | **Җаваплы кешеләр** | **Үтәлеш** |
|---|---|---|---|---|
| **1.** | Төркемнең яңа уку елына әзерлеген | Сентябрь | Мөдир | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | тикшерү. | | | |
| 2. | Көн режимы үтәлешен тикшерү. | Октябрь | Мөдир | |
| 3. | Рус теленә өйрәтү шөгелен тикшерү. | Ноябрь | Мөдир | |
| 4. | ФГОС буенча шөгельгә анализ ясау. | Ел дәвамында | Мөдир | |
| 5. | Балаларның тукландыру графигын контрольдә тоту. | Ел дәвамында | Мөдир | |
| 6. | Төркемнең чыныктыру чараларын үткәрүне контрольдә тоту. | Ел дәвамында | Мөдир | |
| 7. | Төркемдә культура – гигиена кагыйдәләрен дөрес үтәлешен контрольдә тоту. | Ел дәвамында | Мөдир | |
| 8. | Тәрбиячененң, календарь планнарын вакытында төзүләрен тикшереп тору. | Ел дәвамында | Мөдир | |
| 9. | Иртәнге гимнастиканың системалы һәм программа таләпләренә туры китереп үткәрелүен контрольдә тоту. | Ел дәвамында, системалы рәвештә | Мөдир | |
| 10. | Балалар иртәләрен, музыкаль күңел ачуларны, физкультура мавыктыргыч уеннарны оештыруны һәм үткәрүне контрольгә алу. | Ел дәвамында | Мөдир | |

## 7.2 ТЕМАТИК ТИКШЕРҮЛӘР

| **№ п/п** | **Үткәреләчәк чаралар** | **Үткәрү вакыты** | **Җаваплы кешеләр** | **Үтәлеш** |
|---|---|---|---|---|

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 1. | “Федераль дәүләт белем бирү стандартларына нигезләнеп белем һәм тәрбия бирүнең торышын тикшерү, балаларны рус теленә өйрәтү буенча эшнең нәтиҗәлелеге” | Ноябрь | Мөдир | |
| 2. | “Балаларның сәламәтлеген ныгытуда уңайлы шартлар булдыру, хәрәкәт активлыгын арттыруның торышы” | Февраль | Мөдир | |

# VIII. ЭТНО – МӘДАНИ ТӨБӘКАРА ҖЫЕЛМАНЫ ТОРМЫШКА АШЫРУ БУЕНЧА ЭШ

| № п/п | Эшчәнлек төре | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| | **Педагогик процессны баету һәм тулыландыру** | | |
| 1. | «Татар орнаменты» дигән темага төркемдә альбомнар ясау | Ел буе | Тәрбияче |
| 2. | «Мәгариф», «Салават күпере», «Сабантуй», «Мирас», «Көмеш кыңгырау», «Тәрбия» газеталарын һәм журналларын яздыру | Ел буе | Мөдир |
| 3. | Татар һәм рус телләрендә язылган күргәзмә һәм дидактик кулланмалар сатып алу | Ел буе | Мөдир, тәрбияче |
| 4. | Татар телендә булган аудио, видео кассеталар, компакт-дисклар, компьютер программаларын тулыландыру | Ел буе | Мөдир |
| 5. | ЭРК почмагын милли музыка кораллары белән тулыландыруны дәвам итү | Ел буе | Тәрбияче |
| 6. | Милли костюмнар коллекциясен тулыландыруны дәвам итү | Ел буе | Мөдир, тәрбияче |
| 7. | Төркемдә милли почмакны баету | Ел буе | Тәрбияче |
| 8. | Методик кабинетны милли тәрбия буенча әдәбият, дидактик уеннар һәм кулламалар белән тулыландыруны дәвам итү | Ел буе | Мөдир |
| 9. | Төркемдә китап почмакларын яңа балалар өчен чыккан әдәбият исәбенә яңарту | Ел буе | Тәрбиячесе |

# IX. ӘТИ – ӘНИЛӘР БЕЛӘН ЭШ

## 9.1 ГОМУМИ ӘТИ – ӘНИЛӘР ҖЫЕЛЫШЫ

| | Эш төре | Вакыты | Җаваплы | Үтәлеш |
|---|---|---|---|---|

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | Җыелышлар: | | | |
| 1. | *Тема:* Яңа уку елы алдында торган бурычлар.<br>*Көн тәртибе:*<br>1.ТР Мәгариф һәм фән министрыгы 2017 елның 27 декабрендә язылган 2598/17 номерлы “Балалар бакчасында белем бирү эшчәнлеген планлаштыру” дип аталган документ белән әти – әниләрне таныштыру.<br>2. Документ буенча фикер алышу.<br>3. Ата-аналар комитетын саулау.<br>4. Еллык план, балалар бакчасы режимы, шөгылләр челтәре белән таныштыру. | Сентябрь | Мөдир<br>Тәрбияче | |
| 2. | *Тема:* “Физик тәрбия бирү үсешен ФДББС таләпләренә туры китереп белем- тәрбия бирү эшен оештыру”.<br>*Көн тәртибе:*<br>1. “ Балалар бакчасында һәм гаиләдә сәламәт яшәү рәвеше булдыру”.<br>2. “Мәктәпкәчә яшьтәге балаларга кече яшьтән юл йөрү кагыйдәләрен өйрәтү, тормыш иминлекләрен саклау” дигән темага чыгыш. | январь | Мөдир<br>Тәрбияче | |
| 3. | *Тема:* Балаларда ана телендә һәм икенче дәүләт теле буларак рус телендә аралашуга үстерешле телләр тирәлеге тудыру, УМК ны нәтиҗәле файдалану аша кызыксыну тәрбияләү.<br>*Көн тәртибе:*<br>1. “Балаларның ике дәүләт телен өйрәтүдә гаиләнең роле” дигән темага мөдирнең чыгышы.<br>2. “Картиналар, әкиятләр аша балаларның сөйләмнәрен үстерү” дигән темага тәрбияченең чыгышы.<br>3.Бала мэктэпкэ эзерме? Тэрбияче чыгышы | апрель | Мөдир<br>Тәрбияче | |
| | Консультацияләр<br>1.Ата – аналарны “Мәгариф” һәм “Мәгърифәт” газета – журналларында чыккан мәгълуматлар белән таныштырып тору.<br>2.Балаларны матур итеп сөйләшергә өйрәтү. | Ел дәвамында<br><br>Сентябрь | | |

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| | 3.Балада хезмәткә сөю тәрбияләү. Ата-аналар белән анкетирование үткәрү ( Моя роль в подготовке ребёнка к труду и ранней профориентации)<br>4.Балаларның сәламәтлегенә һәм физик үсешенә игътибарны көчәйтү.<br>5.Балаларның сорауларына ничек итеп дөрес җавап бирергә.<br>6.Баланың ялын дөрес оештыру.<br>7.Балада уку хезмәтенә уңай халәт тудыру.<br>8.Баланы матур әдәбиятне яратырга ничек өйрәтергә. | Октябрь<br>Ноябрь<br>Декабрь<br>Январь<br>Февраль<br>Апрель | | |

# 9.2 ӘТИ – ӘНИЛӘР БЕЛӘН ЭШ ПЛАНЫ

| № | Эшнең эчтәлеге | Үткәрү вакыты | Җаваплылар |
|---|---|---|---|
| 1 | Устав, Балалар бакчасының коллдоговоры һәм эш планы белән танышу | Сентябрь | Комиссия членнары |
| 2 | Ата-аналар комитетының эш планын төзүдә катнашу | Октябрь | Комиссия членнары |
| 3 | Гаиләнең тормыш-көнкүрешен , балаларны тәрбияләү шартларын өйрәнү | Ел барышында | Комиссия членнары |
| 5 | Стендлар ясау:<br>“Бала һәм гаилә”<br>“Ата-аналар – безнең ярдәмчеләр” | Ел барышында | Тәрбияче<br>Комиссия членнары |
| 7 | Төркемдә тәрбия һәм белем бирүнең торышы турында ата-наларга мәгълүмат бирү | Ел барышында | Тәрбияче |
| 8 | Ата-аналар җыелышларында катнашу һәм уздыруга хәзерлек алып бару | Даими | Комиссия членнары |
| 10 | Балалар бакчасында бәйрәмнәр үткәрүдә ярдәм итү | Ел барышында | Комиссия членнары |
| 11 | Ата-аналар комитетының эшенә нәтиҗә ясауда катнашу (отчет) | Август | Комиссия членнары<br>Тәрбияче, мөдир |
| 13 | Ашату нормаларын тикшерү, контрольдә тоту | Даими | Комиссия членнары |
| 14 | Җиһазларны ремонтлауда булышу | Даими | Комиссия членнары |

# X. АДМИНИСТРАТИВ-ХУЖАЛЫК ЭШЛӘРЕ

| № п/п | Эшләнәсе эшләр | Үткәрү вакыты | Җаваплы кешеләр |
|---|---|---|---|
| **1.** | Төркемдә тиешле маркировкадагы мебель (өстәл, урындыклар) белән тәэмин итү | Ел дәвамында | Мөдир |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2. | Балалар мебелендәге маркировканы яңарту | август | Тәрбияче |
| 3. | Яшелчә складын яшелчә саклау өчен әзерләү | август | Мөдир |
| 4. | Кышка житәрлек бәрәңге һәм яшелчә әзерләү | сентябрь | Мөдир |
| 5. | Балалар бакчасы бинасын кышка әзерләү (ишек, тәрәзәләрне ныгыту, җылыту) | октябрь | Мөдир |
| 6. | Клумбаларга күпъеллык чәчәкләр утыртуны дәвам итү | сентябрь | Мөдир |
| 7. | Кар көрәү өчен эш кораллары белән тәэмин итү | август | Мөдир |
| 8. | Яктырту системасыннан һәм судан дөрес һәм экономияле файдалану | ел дәвамында | Мөдир |
| 9. | Кер юу машиналарын һәм үтүкләрне ремонтлау һәм яңарту | сентябрь | Мөдир |
| 10. | Балалар бакчасы территориясендә оештыру эшләре: куакларны тигезләп кисү, агачларның корыган ботакларын кисү, яңа куаклар утырту, яшелчә һәм җиләк-җимеш бакчасын казу, чүп үләннәреннән чистарту, яшелчә бакчасын тәртиптә тоту өчен даими рәвештә санитар чәршәмбеләр оештыру | сентябрь | Мөдир |
| 11. | Төркемне булдыра алган кадәр уенчыклар белән тәэмин итү | ел дәвамында | Мөдир |
| 12. | Сәхнәләштерү өчен персонаж костюмнарын белән тулыландыру | ел дәвамында | Тәрбияче |
| 13. | Булдыра алганча куллануга яраксыз хуҗалык инвентарен, савыт-сабаларны яңага алыштыру һәм гамәлдән чыгару | ел дәвамында | Мөдир |
| 14. | Техник куркынычсызлык кагыйдәләрен төгәл үтәү | ел дәвамында | Мөдир |
| 15. | Тәрбиячеләрне булдыра алганча канцелярия товарлары белән тәэмин итү | ел дәвамында | Мөдир |
| 16. | Ватылган яки чатнаган тәрәзә пыялаларын яңага алыштыру | сентябрь | Мөдир |
| 17. | Группаларда косметик ремонт эшләрен башкару | июль | Балалар бакчасы хезмәткәр ләре |

## XI. СӘЛАМӘТЛӘНДЕРҮ, ЧЫНЫКТЫРУ ПЛАНЫ.

| № | Эш төре | Җаваплы кеше | Вакыты |
|---|---|---|---|
| 1. | Бакчаның еллык “Балаларның сәламәтләндерү, чыныктыру планын”төзү. | Август | Мөдир, Тәрбияче |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 2. | ФИЗО почмакларын, спорт участокларын яңарту, атрибутлар белән тулыландыру. | даими | Мөдир тәрбияче. |
| 3. | Максатчан экскурсияләр оештыру. | даими | Тәрбияче |
| 4. | Хәрәкәтле уеннар өчен кулланма җиһазлар туплау | даими | Тәрбияче |
| 5. | Физкультура бәйрәмнәре уздыру. | елга ике | Тәрбияче |
| 6. | Хәрәкәт үстеру буенча күңел ачу кичәләре.<br>РБ педиатры тарафыннан балаларны тикшерүләр, әңгәмәләр.<br>Диагностик тикшерүләр. | айга бер<br>кварталга бер<br>елга ике | Тәрбияче |
| 7. | Иртәнге гимнастикаларны, физкультура шөгыльләрен үз югарылыгында үткәрү | Даими | Тәрбияче |
| 8. | Санитария гигиена таләпләрен үтәү | Даими | Тәрбияче, тәрб. ярдәмчесе |
| 9. | Ата-аналар белән балаларның сәламәтлекләре турында әңгәмәләр уздыру. | Даими | Мөдир тәрбияче |
| 10. | Прогулкаларда хәрәкәтле уеннарны тиешенчә үткәрү | даими | тәрбияче |

## XII. ТЕРРОРИЗМГА КАРШЫ ҮТКӘРӘ ТОРГАН ЧАРАЛАР ПЛАНЫ

| № | Эш төре | Җаваплы кеше | Вакыты |
|---|---|---|---|
| 1. | Балалар бакчасында куркынычсызлык режимын көчәйтү. Буш бүлмәләрне бикләп тору, япканда тикшереп китү, килгәч карап чыгу; | Даими | Мөдир |
| 2. | Бинада билгесез әйбер табылса, эшне туктатып, җирле үзидарәгә хәбәр итү; | Даими | Коллектив |
| 3. | Эвакуация планы белән кабаттан таныштыру; | Август | Мөдир |
| 4. | Беренче ярдәм күрсәтү чараларын өйрәнү; | Сентябрь | Мөдир |
| 5. | Таныш булмаган кешене бинага кертмәү. | Даими | Коллектив |
| 6. | Терроризм турында приказны үтәү. Террор турында сигнал булса, эшне туктатып телефон аша хәбәр итәргә. | Даими | Мөдир |
| 7. | Продукция складын бикләп тоту (агулану очрагы булмасын өчен). | Даими | Мөдир |
| 8. | Бәйрәм, ял көннәрендә бинаны тикшерү буенча дежурство оештыру. | Даими | Мөдир |

## XIII. КОРРУПЦИЯГӘ КАРШЫ КӨРӘШ АЛЫП БАРУ БУЕНЧА ЭШ ПЛАНЫ

| № | Эш төре | Җаваплы кеше | Вакыты |
|---|---|---|---|

| | | | |
|---|---|---|---|
| 1 | “Коррупциягә – юк!” папкасын яңарту | Мөдир | Даими |
| 2 | Хөкүмәт тарафыннан коррупциягә каршы эшчәнлек буенча чыгарылган документларны өйрәнүгә тәкъдим итү | Мөдир | Ел дәвамында |
| 3 | Коррупциягә каршы эшчәнлек буенча һәртөрле методик әдәбият булдыру өстендә эш. | Мөдир, тәрбиячеләр | Ел дәвамында |
| 4 | Ата-аналар җыелышларында чыгышлар. | тәрбиячеләр | График буенча |